ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 01 2023 г. № 43

Түбән Кама муниципаль районының мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре эшчәнлеге өлкәсендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары бирү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районының мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре эшчәнлеге өлкәсендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре әгъзаларына Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсенә караган Түбән Кама муниципаль районының мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре тарафыннан уздырыла торган музейлар, мәдәни-ял, мәдәни-тамаша һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә башка чараларны бушлай карау хокукы бирергә.

2. Тамашачыларны залда индивидуаль-аерым урыннарга утырту таләпләрен үтәүне исәпкә алып, Түбән Кама муниципаль районы мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре тарафыннан мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә мәдәни-ял, мәдәни-тамаша һәм башка чаралар үткәргәндә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре әгъзасына, әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасына хокук алу өчен, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре кассасына мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә чара уздыру көненә кадәр 5 календарь көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итәргә кирәк дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хәрби хезмәт узу чорында карала дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә урнашкан дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә, мәдәни-ял, мәдәни-тамаша чараларын һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә башка чаралар үткәргәндә, әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын бирүне тәкъдим итәргә.

5. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Мәхмүтов А. Г.):

әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының ведомство карамагындагы муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә урнашкан дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре җитәкчеләре игътибарына җиткерергә;

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство карамагындагы оешмалары тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсенең һәр әгъзасына социаль ярдәм чараларына хокукны раслаучы махсус карталар бирүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын тиешенчә гамәлгә ашыруны контрольдә тотарга.

6. Түбән Кама муниципаль районының муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре җитәкчеләренә Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

7. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 17 октябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874